МИНИСТЕРСТВО ОБРАЗОВАНИЯ И НАУКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

06.02.2017 Казан шәһәре № под-165/17

2017 елда Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «Уңышлы мәктәп» грантын гамәлгә кую турында

Татарстан Республикасында теркәлгән һәм үз эшчәнлекләрен билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашыручы, белем бирү эшчәнлегендә югары нәтиҗәләргә ирешүне, мәктәп педагогик коллективының һөнәри үсешен тотрыклы тәэмин итә торган теләсә нинди милек формалы гомуми белем бирү оешмаларында белем бирү сыйфатын күтәрү һәм аларга ярдәм күрсәтү, белем бирү-тәрбия процессын оештыру, социаль-мәдәни мохитне үстерү өлкәсендә учреждениеләр эшенең уңай тәҗрибәсен тарату максатында б о е р а м:

1. 2017 елда Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «Уңышлы мәктәп» грантын гамәлгә кую.

2. 2017 елда Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында (алга таба - Конкурс) 2017 елның 13 мартыннан 27 апреленә кадәр «Уңышлы мәктәп» грантын алуга конкурс оештырырга һәм үткәрергә.

3. Кушымта итеп бирелә торган:

3.1. 2017 елда Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «Уңышлы мәктәп» грантын алуга конкурс әзерләү һәм үткәрү буенча чаралар планын;

3.2. 2017 елда Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «Уңышлы мәктәп» грантын алуга конкурс оештыру һәм үткәрү буенча календарь планын;

3.3. 2017 елда Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «Уңышлы мәктәп» гранты турында Положениене **расларга**.

4. Структур бүлекчәләр җитәкчеләренә һәм чараларны гамәлгә ашыру өчен җаваплы затларга әлеге боерыкның 3.1, 3.2. пунктлары белән расланган планнар үтәлешен тәэмин итәргә;

5.«Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» дәүләт автоном өстәмә һөнәри белем бирү учреждениесенә (Р. Бәдриевага) Конкурсның төбәк этабын оештыру-методик яктан тәэмин итәргә.

6.Бухгалтерлык исәбе һәм хисаплылык бүлегенә (Г. Ф. Гатиятуллинага) чараны оештыру һәм үткәрү белән бәйле конкурсны финанслауны тәэмин итәргә.

7.Әлеге боерык үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры урынбасары-министр Э.Н.Фәттахов

Расланган
Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгының
2017 елның 6 февралендәге
№ под-165/17 боерыгы белән

Татарстан Республикасында 2017 елда Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «Уңышлы мәктәп» грантын алуга конкурс әзерләү һәм үткәрү буенча чаралар планы

| № п/п | Чара | Җаваплы |
|---|---|---|
| 1 | Конкурска әзерлек һәм аны үткәрү буенча гомуми җитәкчелек | Мухаметов И.Р.<br>Федорова Т.Т. |
| 2 | Конкурс үткәрү буенча смета төзү | Гатиятуллина Г.Ф.<br>Имамова Г.К. |
| 3 | Конкурс үткәрү программасын төзү | Федорова Т.Т.<br>Ахмерова Г.Р. |
| 4 | Конкурс сынаулары расписаниесен төзү | Бадриева Р.Р.<br>Ахмерова Г.Р.<br>Мартьянова О.В. |
| 5 | Хисап комиссиясе эшен оештыру | Федорова Т.Т.<br>Ахмерова Г.Р.<br>Мартьянова О.В.<br>Алексеева М.В. |
| 6 | Бәйгене үткәрү көннәрендә фото һәм видеога төшерү.<br>Массакүләм мәгълүмат чаралары тарафыннан конкурс барышын яктыртуны оештыру. | Мухаметова А.Д. |
| 7 | Жюри эшен координацияләү һәм тәэмин итү | Федорова Т.Т.<br>Ахмерова Г.Р.<br>Бадриева Р.Р. |
| 8 | Конкурс үткәрүне оргтехника белән тәэмин итү. | Кравцов А.А. |

Расланган
Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгының
2017 елның 6 февралендәге
№ под-165/17 боерыгы белән

2017 елда Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «Уңышлы мәктәп» грантын алуга конкурс оештыру һәм үткәрү календарь планы

| № п/п | Чара | Үтәлеш вакыты | Җаваплы |
|---|---|---|---|
| 1 | Конкурсны оештыру һәм үткәрүмәсьәләсе буенча оештыру комитеты киңәшмәсе | 2017 елның гыйнвар ае | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы (алга таба-ТР Мәгариф һәм фән Министрлыгы) |
| 2 | Директорлар Советы президиумында конкурс шартлары турында фикер алышу | 2017 елның февраль ае | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 3 | Укыту- методик эш буенча директор урынбасарлары белән киңәшмә | 2017 елның февраль ае | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 4 | Муниципаль районнар башкарма комитетларының мәгариф бүлекләре (идарәләре) башлыклары белән киңәшмә | 2017 елның февраль ае | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 5 | Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы һәм «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» дәүләт автоном өстәмә һөнәри белем бирү учреждениесе (алга таба- «ТР Мәгарифне үстерү | 2017 елның март ае | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, “ТР Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | институты " өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе) сайтларында конкурс турында норматив методик материалларны урнаштыру | | |
| 6 | Конкурста катнашырга теләүчеләрне "ТР Мәгарифне үстерү институты" өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт бюджет һөнәри белем бирү учреждениесе сайтында теркәү | 2017 елның 13 мартына кадәр | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы |
| 7 | Грантка тәкъдим ителгән материалларны бәяләү (конкурсның беренче читтән торып катнашу этабы) | 2017 елның 20-24 марты | “ТР Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе, Эксперт комиссиясе |
| 8 | Икенче этапта катнашу өчен грант алырга теләүчеләрнең исемлеген бастырып чыгару | 2017 елның 25 марты | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы,<br><br>“ТР Мәгарифне үстерү институты» белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе |
| 9 | Апелляция кабул итү һәм карау | 2017 елның 27 мартыннан 31 мартына кадәр | “ТР Мәгарифне үстерү институты» белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе, Республика конкурс комиссиясе |
| 10 | Конкурсның икенче этабы | 2017 елның 3-7 апреле | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы, ТР Мәгарифне |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | | | үстерү институты» белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе, |
| 11 | Грант алучылар исемлеген формалаштыру | 2017 елның 10-14 апреле | “ТР Мәгарифне үстерү институты» белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе, Республика конкурс комиссия |
| 12 | Грант алучыларның расланган исемлеген сайтта урнаштыру | 2017 елның 27 апреле | ТР Мәгариф һәм фән министрлыгы |

Расланган
Татарстан Республикасы
Мәгариф һәм фән министрлыгының
2017 елның 6 февралендәге
№ под-165/17 боерыгы белән

2017 елда Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «Уңышлы мәктәп» гранты турында
Положение

1. Гомуми положениеләр

1.1. 2017 елда Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «Уңышлы мәктәп» гранты (алга таба - Грант) Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән гамәлгә куела.

Чарада грантны гамәлгә куючы (грант бирүче) һәм грант алучы катнаша.

Грантны гамәлгә куючы (грант бирүче) - грантлар бирү буенча вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы

Грант алырга теләүче (дәгъва кылучы) - Татарстан Республикасы территориясендә билгеләнгән тәртиптә теркәлгән һәм үз эшчәнлеген гамәлгә ашыручы, соңгы өч елда 3 (өчтән) дә ким булмаган 11 сыйныф чыгарылышы булган теләсә кайсы милек формасындагы гомуми белем бирү оешмасы.

Грант алучы- агымлагы Положениедә билгеләнгән критерий һәм таләпләргә туры килгән, конкурслы сайлап алу узган, 1дән 21 кадәр урын алган Татарстан Республикасы гомуми белем бирү оешмалары.

Грант алучыларга педагогик коллективны һөнәри яктан үстерүгә юнәлдерелгән чараларны тормышка ашыру өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата бүләк- Грант бирелә:

1-10 урын алган ун гомуми белем бирү оешмасы 1 000 000 (бер миллион) сум күләмендә;

11-21 урын алган унбер гомуми белем бирү оешмасы 500 000 (биш йөз мең) сум күләмендә.

Грант алучы 3 елга 1 тапкыр грантта катнашырга хокуклы.

1.2. Грант алучыларны конкурс нигезендә сайлап алу (алга таба - конкурслы сайлап алу) максаты - белем бирү сыйфатын күтәрүне стимуллаштыру һәм Татарстан Республикасында белем бирү эшчәнлегендә югары нәтиҗәләргә ирешүне, мәктәп педагогик коллективының һөнәри үсешен тотрыклы тәэмин итә торган теләсә кайсы милек формасындагы белем бирү оешмаларына, аларның педагогик коллективларына ярдәм итү, мәктәп педагогик коллективының һөнәри үсеше, оешмаларның укыту-тәрбия процессын оештыру өлешендәге уңай эш тәҗрибәсен тарату, социаль-мәдәни мохит булдыру.

1.3. Конкурс сайлап алуының максаты булып, белем бирү эшчәнлегендә, иҗади һөнәри педагогик мохит булдыруда югары нәтиҗәләргә ирешүне тотрыклы тәэмин итүче мәгариф оешмаларын ачыклау һәм бүләкләү тора.

1.4. 2017 елда Татарстан Республикасында Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы кысаларында «Уңышлы мәктәп» грантын алуга Конкурс (алга таба-Конкурс) ачык булу, белем бирү оешмалары укучыларының академик казанышларын исәпкә алып, коллегиальлек принциплары нигезендә үткәрелә.

Конкурс ике этапта үткәрелә:

читтән торып - мәгълүмати материаллар бирү;

төп - гомуми белем бирү оешмасы коллективының һөнәри педагогик осталыгын үстерүгә юнәлдерелгән проектны яклау.

1.5. Конкурсның читтән торып катнашу этабы грантын алуга дәгъва итүчеләрне сайлап алу критериясе булып гомуми белем бирү оешмасының белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләренең суммар күрсәткече тора, ул исәпкә ала:

югары белем бирү нәтиҗәләре күрсәткән гомуми белем оешмалары рейтингын (алга таба-рейтинг);

дәүләт (муниципаль) гомуми белем бирү оешмалары педагогларының Татарстан Республикасында «Россия Ел укытучысы» һөнәри осталык конкурсында (соңгы өч елда муниципаль, зона һәм төбәк этаплары) катнашуы нәтиҗәләрен.

1.6. Рейтинг мәгариф эшчәнлегенең түбәндәге объектив күрсәткечләре нигезендә төзелә:

укучыларның соңгы өч елда динамикада Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасында (региональ һәм йомгаклау этаплары) катнашу нәтиҗәләре;

укучыларның соңгы өч елда динамикада республика олимпиадасында катнашу нәтиҗәләре;

укучылар соңгы өч елда динамикада бердәм дәүләт имтиханнары (белем бирү оешмасын сайлап алу буенча өч гомуми белем бирү фәне буенча дәүләт имтиханнары нәтиҗәләре исәпкә алына) нәтиҗәләре (динамика карала);

1.7. Рейтинг баллар суммасы ярдәмендә формалаша. Баллар түбәндәге тәртип нигезендә исәпләнә:

1 балл - мәктәп укучыларының Бөтенроссия олимпиадасының төбәк этабы яки республика олимпиадасының һәр призеры өчен;

3 балл - Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасы һәм республика мәктәп укучылары олимпиадасы төбәк этабы җиңүчесе өчен;

5 балл - Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабында һәр призер өчен;

10 балл - Бөтенроссия мәктәп укучылары олимпиадасының йомгаклау этабы җиңүчесе өчен.

2 балл - Татарстан Республикасында «Россиянең “ Ел укытучысы» Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы муниципаль туры призеры;

3 балл - Татарстан Республикасында «Россиянең “ Ел укытучысы» Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы муниципаль туры җиңүчесе өчен;

5 балл - Татарстан Республикасында «Россия Ел укытучысы» Бөтенроссия конкурсының төбәк этабында катнашучы өчен;

6 балл-Татарстан Республикасында «Россиянең Ел укытучысы» Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы номинанты өчен;

7 балл-Татарстан Республикасында «Россиянең Ел укытучысы» Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы лауреаты өчен;

8 балл - Татарстан Республикасында «Россиянең Ел укытучысы» Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы призерлары (2, 3 урын) өчен;

9 балл - Татарстан Республикасында «Россиянең Ел укытучысы» Бөтенроссия конкурсының төбәк этабы җиңүчеләре (1 урын) өчен;

10 балл-Татарстан Республикасында «Россиянең Ел укытучысы» Бөтенроссия конкурсының төбәк этабында абсолют җиңүче өчен.

Укучыларның гомуми белем бирү предметлары буенча олимпиадаларда максималь ирешелгән нәтиҗәләре исәпкә алына (һәр укучының нәтиҗәләре һәрбер фән буенча бары тик максималь нәтиҗә нигезендә бер тапкыр гына исәпкә алынырга мөмкин).

1.8. Бирелгән күрсәткечләр буенча белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләре буенча алынган баллар суммалаштырыла. Гомуми белем бирү оешмалары, баллар кимү тәртибендә, мәгариф эшчәнлеге нәтиҗәләренең суммар күрсәткече буенча рейтингта урнаша

1.9. Грантның турыдан-туры этабында катнашу өчен, белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләренең гомуми күрсәткече буенча 1дән 50гә кадәр урыннар алган Грант дәгъва кылучылар чакырыла.

1.10. Беренче этап нәтиҗәләре буенча эксперт комиссиясе конкурсның икенче этабында катнашу хокукына ия булган грантка дәгъва кылучыларның тигез (өстенлекләрсез) исемлеге төзелә һәм Республика конкурс комиссиясенә тапшырыла.

Республика конкурс комиссиясе грантка дәгъва кылучыларны икенче этапка чыгару турында Карар кабул итә, ул Татарстан Республикасы мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтында бастырыла.

1.11. Конкурсның беренче этабын үткәрү нәтиҗәләре белән килешмәгән очракта, грантка дәгъва кылучы Республика конкурс комиссиясенә апелляция бирергә хокуклы. Апелляция, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтында грантка дәгъва кылучыларны конкурсның икенче этабына чыгару турында Республика конкурс комиссиясе карары

басылып чыккан көннән башлап, эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек срокта, «ТР Мәгаифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү учреждениесенең рәсми сайтының «Грантлар» бүлеге, «Татарстан Республикасының уңышлы мәктәбе» бите аша грантка дәгъва кылучы тарафыннан Республика конкурс комиссиясе рәисе исеменә ирекле язма рәвештә бирелә.

1.12.Апелляцияне Республика конкурс комиссиясе, апелляция бирү вакыты тәмамланганнан соң, эш көннәрендә исәпләнгән ике көнлек срокта карый. Республика конкурс комиссиясе, конкурс материалларын бәяләгәндә, Эксперт комиссиясе тарафыннан хокук бозулар булган-булмаганны билгели, шулай ук бәяләү балларын аргументацияләү өчен экспертларны чакыру хокукына да ия. Апелляцияне карау нәтиҗәләре буенча Республика конкурс комиссиясе түбәндәге карарларның берсен чыгара:

апелляцияне кире кагу һәм игълан ителгән нәтиҗәләрне саклап калу турында;

апелляциядән канәгатьләнү, грантка дәгъва кылучыны икенче этапка чыгару һәм аны икенче этапта катнашучылар исемлегенә кертү турында.

Апелляция буенча Республика конкурс комиссиясе карарлары гади күпчелек тавыш белән кабул ителә. Тавышлар тигез булган очракта, Республика конкурс комиссиясе рәисе хәлиткеч тавыш бирергә хокуклы.

1.13. Апелляцияне Республика конкурс комиссиясе тарафыннан карау комиссия утырышында катнашучы Республика конкурс комиссиясе рәисе һәм комиссиянең барлык әгъзалары кул куйган беркетмә белән рәсмиләштерелә.

1.14. Конкурсның турыдан-туры этабы эссе (презентация) һәм белем бирү проектын яклаудан гыйбарәт.

Конкурсның читтән торып үткәрелгән этабында җиңгән һәр мәгариф оешмасыннан 5 кешелек команда, шул исәптән мәктәп администрациясе вәкилләре, педагогик хезмәткәрләр, укучылар һәм ата-аналар җәмәгатьчелеге вәкилләре җибәрелә, ул эссе рәвешендә компьютер презентация яклый :

а) Эссе «Уңыш, уңышлылык, уңышлы мәктәп - нәрсә ул?»

Максат: Уңышка ирешү технологияләрен формалаштыру сәләтен.

Белем бирү оешмасының үсеш перспективаларын күрә һәм аны алга таба камилләштерү өчен куллана белү сәләтен күрсәтү. Белем бирү оешмасы эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген анализлау сәләте.

Конкурс чарасы форматы: эссе тексты (5 биткә кадәр; шрифт- Times New Roman, кегль - 12, интервал - 1,5, кырлар 2 см).

Бәяләү критерийлары:

тел һәм мәгълүмати грамоталылык;

мәктәп миссиясен аңлау;

үз позициянңе дәлилләү осталыгы;

кыйммәт ориентирлары булуы;

тәгъбир итү оригинальлеге;

этик нормаларны үтәү (саклау).

б) Аны «уңышлы мәктәп»буларак билгеләргә мөмкинлек бирә торган,

эсседә бәян ителгән нигезләмәләрнең белем бирү оешмасының теге яки бу өлкәсендәге эшчәнлегенең конкрет казанышларын күрсәткән практикада проиллюстрацияләнгән формадагы компьютер презентациясе.

Максат: Белем бирү оешмаларын теге яки бу эшчәнлек өлкәсендәге казанышларының конкрет мисаллары ярдәмендә сурәтләү. Белем бирү оешмасы эшчәнлеге тәҗрибәсен анализлау һәм тәкъдим итү сәләтен күрсәтү. Билгеле бер белем бирү оешмасына хас кыйммәт ориентирларны тәкъдим итү.

Конкурс форматы: 15 слайд күләмендә PowerPoint компьютер презентациясе, аңа 5бит күләмдә аңлатма язуы ( шрифт -Times New Roman, кегль - 12, интервал - 1,5, кырлар(читләр) - 2 см).

Бәяләү критерийлары:

тәкъдим ителгән мәктәпнең уңышлылыгына ирешү методикаларының һәм технологияләрнең оригинальлеге;

мәктәпнең уңышлы булуын күзаллауның бөтенлеге;

тәҗрибәнең нәтиҗәлелеге һәм гамәли диссеминациясе;

оригинальлек һәм инновациялелек;

мәгълүмати культура;

үзбәяләүнең объективлыгы;

мәктәпнең кыйммәтле ориентирларын  (миссиясен) тәкъдим итү;

белем бирү процессында катнашучыларның үзара хезмәттәшлеген һәм тәэсирен (йогынтысын) күрсәтү;

мәктәпнең уңышына ирешүдә системалы-эшлекле һәм интерактив алымнар куллану.

Сайлап алу материаллары Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының рәсми сайтларында,  «Интернет» мәгълүмат-коммуникация челтәрендә һәм«Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» » өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе (алга таба- «Т Р Мәгарифне үстерү институты ") «Грантлар» бүлегендә урнаштырылган.

1.15.Төп этап педагогик коллективның һөнәри осталыгын үстерүгә юнәлдерелгән белем бирү проектын яклау рәвешендә үткәрелә.

1.16. Проектны яклау презентация рәвешендә (кәгазь һәм электрон чыганакта) гомуми белем бирү оешмасы җитәкчесе тарафыннан башкарыла.

1.17. Проектны яклауга 10 минуттан артык булмаган  вакыт бирелә.

1.18. Конкурс сайлап алуы критерийлары булып түбәндәгеләр тора:

гомуми белем бирү оешмалары алдында куелган бурычларны исәпкә алып, тәкъдим ителә торган эшләнмәнең актуальлеге, яңалыгы, максатчанлыгы;

тәкъдим ителгән проектны массакүләм практикада (тәҗрибәдә)  куллану (тиражлау) мөмкинлеге, нәтиҗәлелеге, ихтыяҗы,;

проектны гамәлгә ашыру өчен беренчел база булу;

социаль партнерлар булу;

проектны гамәлгә ашыруның конкрет нәтиҗәләрен фаразлау һәм аны гамәлгә кертүне бәяләү механизмы булу;

проектның технологиялелеге.

1.19. Конкурс сайлап алуының һәр критериясе буенча максималь балл-10 балл.

Баллар һәр критерий буенча исәпләнә һәм кушыла.

1.20. 2017 елда Татарстан Республикасында «Уңышлы мәктәп» гранты белем бирү эшчәнлеге нәтиҗәләренең суммар күрсәткече һәм проектны яклау нәтиҗәләре буенча 1-21 урынга чыккан гомуми белем бирү оешмаларына тапшырыла.

Грант алучылар республика конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнә һәм Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.

1.21. «ТР Мәгарифне үстерү институты»дәүләт өстәмә һөнәри белем бирү учреждениесе электрон рәвештә конкурста катнашу өчен гаризалар бирү операторы булып тора.

1.22. Грант бирү турындагы карар грант алуга конкурста һәм грантны гамәлгә ашыру чорында директор турында белә торып ялган яки дөрес булмаган мәгълүматларны ачыклаганда кабул ителми.

## II. Конкурста катнашу өчен гаризалар бирү

2.1. Грант алуга дәгъва кылучыларга Татарстан «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү учреждениесенең рәсми сайты «грантлар» бүлеге, «Татарстан Республикасының уңышлы мәктәбе» бите аша, 2017 елның 13 мартыннан да соңга калмыйча, Республикасы муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының мәгариф идарәсе (бүлеге) җитәкчесе тарафыннан расланган гариза тапшырырга кирәк

2.2. Гариза 2017 елның 13 мартыннан соң бирелгән очракта, Грант алырга теләүче конкурста катнашу хокукыннан мәхрүм ителә.

## III. Конкурсны үткәрү тәртибе

3.1. Грант алуга Конкурс Татарстан Республика мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы нигезендә үткәрелә.

3.2. Грант бирүче гаризалар кабул итү вакыты тәмамланганчы,10 эш көненнән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән

министрлыгының рәсми сайтында һәм «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты " өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесе сайтында мәгълүмат урнаштыру юлы белән конкурс үткәрү турында игълан итә.

3.3. 2017 елның 13 мартына кадәр Грант алуга дәгъва кылучылар «Татарстан Республикасы Мәгарифне үстерү институты» өстәмә һөнәри белем бирү дәүләт автоном мәгариф учреждениесенең рәсми сайты «грантлар» бүлегенә, Татарстан Республикасында «Уңышлы мәктәп» битләренә гариза бирәләр.

3.4. Конкурс материалларын бәяләү һәм проектны яклау өчен 11 әгъзадан торган Республика конкурс комиссиясе һәм 20 әгъзадан торган Эксперт комиссиясе оештырыла.

3.5. Республика конкурс, эксперт комиссияләре утырышлары кирәк булган саен уздырыла һәм, аларда комиссия составының яртысыннан артыграгы катнашса, хокуклы дип санала.

3.6. Әгәр катнашучыларның күпчелеге тавыш бирсә, Республика конкурс комиссиясе карарлары кабул ителгән саналалар. Әгәр тавыш бирүчеләр саны тигез (бер үк күләмдә) булса, Республика конкурс комиссиясе рәисенең тавышы хәлиткеч була.

3.7. Грант алуга конкурсны оештыру-методик яктан тәэмин итү һәм уздыруны составында рәис, җаваплы сәркатиб, матбугат секретаре һәм әгъзалары булган Республика конкурс комиссиясе гамәлгә ашыра.

3.8. Республика конкурс комиссиясенең шәхси составы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.

3.9. Республика конкурс комиссиясе:

массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка ысуллар аша конкурсны үткәрү шартлары, тәртибе һәм вакытлары турында игълан итә;

катнашучылардан гаризалар һәм материаллар кабул итә;

эксперт комиссиясен туплый;

грант алуга бирелгән материалларга бәйсез экспертиза оештыра;

Конкусның беренче (читтән торып катнашу) һәм икенче (төп) этапларын үткәрә;

аппеляцияләрне карый;

Конкусның беренче (читтән торып катнашу) һәм икенче (төп) этапларына йомгак ясый;

Конкурска йомгак ясау һәм җиңүчеләрне бүләкләү тантанасын оештыра;

Конкурс нәтиҗәләрен һәм иң яхшы материалларны бастыру эшен оештыра.

3.10. Конкурс материалларын бәяләү өчен рәис һәм әгъза составында Эксперт комиссиясе төзелә.

3.11. Эксперт комиссиясенең персональ составы Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы боерыгы белән раслана.

3.12. Конкурс материалларын экспертиза уздырганда, эксперт комиссиясе эшенә бәйсез экспертлар җәлеп ителә ала.

3.13. Экспертлар сыйфатында:

Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән Министрлыгы;

педагогик хезмәткәрләрнең өстәмә һөнәри белем бирү төбәк оешмалары;

югары һөнәри белем бирү оешмалары;

җәмәгатьчелек вәкилләре җәлеп ителергә мөмкин.

3.14. Конкурс материалларын экспертизалаганда:

тәкъдим ителгән материалларны бәяләү критерийлары нигезендә бәяләүнең объективлыгы;

конфиденциальлек (шул исәптән конкрет катнашучыны бәяләүдә катнашмаган эксперт комиссиясе әгъзаларына карата да) тәэмин ителә.

3.15. Грант алуга конкурсның икенче (турыдан туры) этабында катнашучыларны бәяләү эксперт комиссиясе әгъзалары тарафыннан катгый бәя бирү критерийлары нигезендә эксперт бәяләве методы белән гамәлгә ашырыла.

3.16. Эксперт комиссиясе:

билгеләнгән вакытта, әлеге Положениедә билгеләнгән критерийлар нигезендә, читтән торып катнашу һәм көндезге этаплара грантка дәгъва кылучыларның конкурс материалларын һәм эшләрен бәяләүне үткәрә;

баллар эксперт битләренә кертелә, эксперт имзасы белән таныклана һәм эксперт комиссиясе рәисенә тапшырыла;

эксперт битләре нигезендә грантка дәгъва кылучыларның рейтингы төзелә. Эксперт комиссиясе рәисе һәм әгъзалары кул куйган Рейтинг Республика конкурс комиссиясенә тапшырыла.

3.17. Эксперт комиссиясе 2017 елның 20-24 мартына кадәр бирелгән гаризаларны карый, читтән торып катнашу этабында булган грантка дәгъва кылучыларның эшләренә экспертиза үткәрә.

3.18. Эксперт комиссиясенең эш нәтиҗәләре буенча конкурсның турыдан-туры этабында катнашу өчен грантка дәгъва кылучыларның исемлеге төзелә һәм раслана.

3.19. Конкурсның турыдан-туры этабы 2017 елның 3-7 апрелендә Казан шәһәрендә уза. Эксперт комиссиясенең эш нәтиҗәләре буенча грантка дәгъва кылучыларның рейтингы төзелә һәм республика конкурс комиссиясенә тапшырыла.

3.20. 2017 елның 10 апреленнән 14 апреленә кадәр конкурсның турыдан-туры этабы йомгаклары буенча республика конкурс комиссиясе грант алучылар исемлеген төзи.

3.21. Грант бирүче 2017 елның 27 апрелендә Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының htpp//: mon.tatar.ru/ сайтында “Укытучыларга грантлар/ Татарстан мәктәапәре”Уңышлы”мәктәбе” бүлегендә грант алучыларның расланган исемлеген катнашында киңәшмә.

## IV. Конкурсны финанслау

Грант бирү максатларында субсидия бирү тәртибе Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.